**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НАРМОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӘТЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НАРМОНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422370, с. Нармонка, ул. Советская , 37А

422370 Нармонка авылы, Совет урамы,37 А

тел. (84373) 5-50-43,e-mail: narm.Tet@tatar.ru

ОГРН 1061672018198, ИНН/КПП 1638005121/163801001

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**11 .03. 2025** **№ 5**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләүне уздыру тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1743 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр турында " 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ::

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләүне уздыруның кушымтада бирелә торган тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә 1 апрельгә кадәр Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге башкарма комитетына хисап елындагы һәм хисап елына кадәрге һәр салым чыгымы буенча белешмәләр җибәрүне тәкъдим итәргә:

- ташламалардан файдаланган түләүчеләр саны турында;
- Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге бюджетының төшеп калучы керемнәре суммалары турында;
- һәр салым чыгымы буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге бюджетына түләүчеләр тарафыннан декларацияләнгән салым күләмнәре турында.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://tetushi.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Җитәкче** Т.А.Хәкимов